ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 11.12.2025 1924 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына электрон аукцион үткәрү тәртибе турында» 2025 елның 23 июлендәге 1196 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 448 статьясы, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» 2013 елның 30 октябрендәге 365 номерлы карары, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләре һәм мәгълүмат конструкцияләре урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 августындагы 1083 номерлы карары карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына электрон аукцион үткәрү тәртибе турында» 2025 елның 23 июлендәге 1196 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның аукцион үткәрү документлары таблицасында 1-13 нче юлларны төшереп калдырырга.

1.2. 4 нче кушымтаның аукцион үткәрү документларындагы реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларында 19, 20, 21, 22, 23, 24 нче битләрне төшереп калдырырга.

1.3. Шартнамәнең 2 нче кушымтасында 1-13 нче юлларны төшереп калдырырга.

1.4. Шартнамәнең 5 нче кушымтасындагы 3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.6. пункты белән тулыландырырга:

«3.6. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» 2013 елның 30 октябрендәге 365 номерлы карары нигезендә айлык түләү күләме билгеләнә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337

Владелец: Томилин Андрей Александрович

Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

А.А. Томилин

Лист согласования к документу № 1924 от 11.12.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 12.12.2025 11:07

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Томилин А.А. | | Подписано 12.12.2025 - 11:14 | - |